# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлегенең Яхшыбай авылы торак пунктында
2022 елда үзара салым кертү турында

**2021 елның 19 нчы ноябре**

**№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Яхшыбай авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яхшыбай авылы Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, хәрби хезмәттәге хәрбиләрдән тыш , яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне ,инвалидлар коне , Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр,
- светодиод яктырткычлар урнаштыру;
- МТЗ-82 тракторын карап тоту( ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу););
- авыл җирлеге торак пунктларындагы юлларны кыш көне кардан чистарту, җәйге вакытта үләннәрне чабу, төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә хезмәт күрсәтү өчен түләү.);-
- Яхшыбай авылы зираты коймаларын янарту очен материал сатып алу;
- «Сарман»район газетасына некрологларны бирү.

3. Әлеге карарны Иске Кәшер авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Н. Дәүләтҗанов